| СОВЕТ КУРНАЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ КӨРНӘЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|---|

**РЕШЕНИЕ** Коры Көрнәлс ав. **КАРАР**

16.03.2020 № 138

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Көрнәле авыл җирлегендә Бюджет корылышы һәм бюджет процессы турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

Гамәлдәге законнарга, шул исәптән «Россия Федерациясе Бюджет кодексына казначылык хезмәте күрсәтү һәм казначылык түләүләре системасына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 27 декабрендәге 479-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләренә туры китерү максатларында

**Көрнәле авыл җирлеге Советы карар кылды:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Көрнәле авыл җирлеге карары белән расланган Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Көрнәле авыл җирлегендә Бюджет корылышы һәм бюджет процессы турында Нигезләмәгә 2015 елның 26 гыйнварындагы 86 номерлы, түбәндәге эчтәлекле:
- 13 маддәнең 16 пунктында «акчаларны исәпкә алу буенча» сүзләрен төшереп калдырырга;
- 30 маддәнең 2 пунктындагы 2 абзасында «кассадагы» сүзен «казначылыктагы» сүзенә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Көрнәле авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Көрнәле авыл җирлеге советы бинасында мәгълүмат стендында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Алексеевск муниципаль районының Көрнәле авыл җирлеге башлыгы, Совет рәисе** **Х.А.Медведев**